Татарстан Республикасының Аксубай
муниципаль районының Шәрбән
авыл җирлеге Советы
423064 ТР Аксубай районы, Шәрбән
авылы, Октябрь урамы, 10, тел. 4-88-
52 Srb.Aks@tatar.ru

Совет
Щербенского сельского поселения
Аксубаевского муниципального района
Республики Татарстан
423064 РТ, Аксубаевский район с.
Щербень, ул.Октябрьская,10 тел. 4-88-52
Srb.Aks@tatar.ru

# КАРАР

**2021 елның 22 марты** **№ 17**

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар буенча вакытында түләнеп бетмәгән салымларны һәм пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип табуның өстәмә нигезләре турында» 2021 елның 5 мартындагы 15 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге Советының 2021 елның 5 мартындагы 15 номерлы "Җирле салымнар буенча вакытында түләнеп бетмәгән салымларны һәм пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип табуның өстәмә нигезләре турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Карарның преамбуласында «Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 19.08.2010 ел, № ЯК-7-8/393@ «Пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча түләнеп бетмәгән салымларны һәм бурычны түләтүгә өметсез дип табылган пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны юкка чыгару тәртибен һәм түләнеп бетмәгән салымларны, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны түләттерүгә ышанычсыз дип тану шартларын раслаучы документлар исемлеген раслау турында» гы Боерыгы сүзләрен Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2019 елның 2 апрелендәге ММВ-7-8/164 санлы «Пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча түләүгә өметсез дип танылган түләнеп бетмәгән салымларны һәм бурычларны бетерү тәртибен һәм түләнеп бетмәгән салымларны, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану шартларын раслаучы документлар исемлеген раслау турындагы” Боерыгы белән алмаштырырга.

1.2. 1 пунктның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

1.3. 2 Пункт үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга .http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:/ / pravo. tatarstan. ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Шәрбән авыл җирлеге Советының финанс һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәрбән авыл җирлеге башлыгы Д.А.Шәрифуллин